**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

Чернышевского ул., д.23, г.Лаишево 422610

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Чернышев урамы, 23 нче йорт Лаеш ш. 422610

Тел: 8-(84378) -2-52-28 Факс: 8-(84378) -2-54-34
e-mail: Ispolkom.Laishevo@tatar.ru

2023 елның 16 феврале 515 номер

# КАРАР

## Татарстан Республикасы, Лаеш муниципаль районы, Габишево авыл җирлеге, Габишево авылы, Приволжская ур. 37, 39,41 йортлар адресы буенча урнашкан күпфатирлы торак йортлар территорияләрен ызанлау проектын әзерләү турында.

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 41,43, 45 статьялары нигезендә «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, территорияне тотрыклы үстерүне тәэмин итү, планлаштыру структурасы элементларын (кварталлар, микрорайоннар, башка элементлар) бүлеп бирү, капиталь төзелеш объектлары урнашкан җир кишәрлекләре чикләрен, линия объектларын төзү һәм урнаштыру өчен билгеләнгән җир кишәрлекләре чикләрен билгеләү максатларында, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы, Лаеш муниципаль районы, Габишево авыл җирлеге, Габишево авылы, Приволжская ур. 37, 39,41 йортлар адресы буенча урнашкан күпфатирлы торак йортлар территорияләрен ызанлау проектын әзерләүгә керешергә.

2. Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 43 статьясы нигезендә проектның эчтәлеген билгеләргә.

3. Гавами тыңлаулар (җәмәгать фикер алышулары) уздыруны исәпкә алып проектны әзерләү срогын 2023 елның 10 августына кадәр билгеләргә.

4. Әлеге карар басылып чыккан вакыттан алып ундүрт көн эчендә физик һәм юридик затларга Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитетына территорияне ызанлау проектының тәртибе, сроклары һәм эчтәлеге турында фикерләр җибәрергә тәкъдим итәргә.

5. Әлеге карарны “Кама ягы”(«Камская новь») район газетасында, Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм интернет

телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында- http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитетының архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлеге башлыгы А.П. Карсаловка йөкләргә.

Җитәкче вазыйфаларын
башкаручы А.Г. Карсалов